ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» марта 2025 ел № 77

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 05.07.2023 елның 193 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасының 19.12.2006 елның 80-ЗРТ номерлы Кодексы нигезендә, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы 30.07.2010 елның 60-ЗРТ номерлы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасының 28.02.2025 елның 7-ЗРТ номерлы Законына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 05.07.2023 елның 193 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегеннән (алга таба-Исемлек) административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 2.19, 2.20 статьялары буенча юлларны төшереп калдырырга

1.2. Исемлектә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 3.10 статьясы буенча юлны әлеге карарга кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 05.07.2023 елның 193 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 25.12.2023 елның 398 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 26.03.2025 елның
77 номерлы карарына 1 нче кушымта

| Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы статьялары | Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге | Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә ведомство буйсынуындагы административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга вәкаләтле органнар |
|---|---|---|
| 3.10 статья.<br>Татарстан Республикасы территориясендәге су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен бозу (гражданнарга карата) | - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктының әйдәп баручы белгечләре;<br>- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторы әйдәүче белгече;<br>- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлеге баш белгече | Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча 1 нче, 2 нче суд участоклары җәмәгать судьялары (Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 7.1 статьясы) |